ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 6 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 86 (I өлеш), № 92 (I өлеш), № 95 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 20 статьяның 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Бер муниципаль берәмлекнең муниципаль милкендәге җир кишәрлекләре аларны Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{5}$ статьясындагы 6 һәм 7 пунктчалары нигезендә аерым категориядәге гражданнарга һәм (яисә) гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциягә карамаган оешмаларга бирү максатларында башка муниципаль берәмлекнең муниципаль милкенә түләүсез тапшырылырга мөмкин.»;

2) 32 статьяның 3 пунктындагы дүртенче абзацында «унсигез яше тулмаган» сүзләрен «өлкән баласы 18 яшькә яисә, ул белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы

оешмада көндезге уку рәвешендә белем алган очракта, 23 яшькә кадәрге» сүзләренә алмаштырырга;

3) $32^1$ статьяда:

а) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Әлеге Кодексның 32 статьясындагы 3 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән максатлар өчен җир кишәрлекләре алырга теләгән шәһәр округы территориясендә даими яшәүче гражданнарга җир кишәрлекләре тиешле шәһәр округы чикләрендә яисә әлеге пунктта каралган муниципаль берәмлекләр чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре исәбеннән бирелә, алар тиешле шәһәр округы милкендә була яисә алар белән идарә итү һәм эш йөртү вәкаләтләре Татарстан Республикасы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә даими яшәүче гражданнарга җир кишәрлекләре Югары Ослан муниципаль районы, Биектау муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы, Лаеш муниципаль районы, Питрәч муниципаль районы чикләрендә бирелергә мөмкин. «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә даими яшәүче гражданнарга җир кишәрлекләре Тукай муниципаль районы чикләрендә бирелергә мөмкин.»;

б) 10 пунктка түбәндәге эчтәлекле 11 пунктча өстәргә:

«11) 18 яшьтән 23 яшькә кадәрге өлкән баланың белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада көндезге уку рәвешендә белем алу фактын раслаучы документ.»;

в) 17 пунктның беренче абзацында «1 – 7 пунктчаларында» сүзләрен «1 – 7, 11 пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;

г) $19^1$ пунктта «бирелгәндә башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары» сүзләрен «бирү максатларында Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пункты, 3 пунктындагы «б» һәм «в» пунктчалары нигезләмәләренең гамәлдә булуы 2024 елның 23 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 14 июнь
№ 40-ТРЗ